ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САРМАШ-БАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРМАШ-БАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Центральная, д.114 , с.Сармаш-Баш
Заинский район, 423532 тел./факс 8(85558) 3-90-30
e-mail: Sbash.Zai@tatar.ru 8(85558) 3-90-30

Үзәк урамы, 114 нче йорт, Сармаш-Баш
авылы, Зәй районы, 423532 тел./факс
e-mail: Sbash.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 23**

**КАРАР**
**от 09.12.2025г**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясендә шундый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюны оештыру һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген раслау турында»**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.12.2014 № 1300 номерлы «Дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирелмичә һәм сервитутлар урнаштырылмыйча урнаштырылырга мөмкин булган объектлар төрләре исемлеген раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.06.2015 № 416 номерлы «Дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирелмичә һәм сервитутлар, публичный сервитутлар урнаштырылмыйча урнаштырылырга мөмкин булган объектлар төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртипне һәм шартларны раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына нигезләнеп.

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Сармаш-Баш авылы территориясендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен кую һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче**
**Сармаш-Баш**
**авыл җирлеге** **Г.П.Абрамов**

Исп.Абрамов Г.П
Тел.8 919 639 09 19

Кушымта
Татарстан Республикасы муниципаль районы
армаш-Баш авыл җирлегенең
2025 елның " 09 " декабрендәге 23 номерлы карарына

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясендә шундый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюны оештыру һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлы корылмаларны һәм (яисә) вакытлы конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары Исемлеге**

| № | Объектның урнашу урыны | Объектның мәйданы кв. м | объект | Объектның урнашу координаталары) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Зәй муниципаль районы, Сармаш-Баш авылы, Сармаш-Баш авыл җирлеге, Үзәк ур., 114а й. | 6 | Сармаш-Баш авыл мәдәният йорты | 55.221250<br>55.343430 |